# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге Кыр Шонталы авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 10 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 10 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Кыр Шонталы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Кыр Шонталы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокլы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау .
2) су манарасы өчен су асты насосын сатып алу .
3) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (фонарьлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү).
4) Техниканы карап тоту: (ягулык-майлау материалларын сатып алу, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү).
5) Спорт мәйданчыгында футбол капкасын урнаштыру.
6) Зиратны төзекләндерү (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 430 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 250 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 250 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлегендәге Кыр Шонталы авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Кыр Шонталы авыл җирлеге»

муниципаль берәмлеге территориясендәге Кыр Шонталы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау .

2) су манарасы өчен су асты насосын сатып алу .

3) торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (фонарьлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү).

4) Техниканы карап тоту: (ягулык-майлау материалларын сатып алу, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү).

5) Спорт мәйданчыгында футбол капкасын урнаштыру.

6) Зиратны төзекләндерү (килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Кыр Шонталы авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Кыр Шонталы авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы Хәммәдиев Ф.Я.

СОВЕТ СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ